| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ЗАКУПКАМ | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ САТЫП АЛУЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

**30.09.2022** № **04-05-180**

Казан шәһәре

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетына килгән ришвәтчелек юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибе турында

2003 нче елның 12 нче маенда кабул ителгән “Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында” 16-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 нче маддәсе нигезендә боерык бирәм:

1. Боерыкка беркетелгән Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетына килгән ришвәтчелек юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү Тәртибен расларга.

2. Түбәндәгеләрне гамәлгә кертергә:

ришвәтчелек юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетында ришвәтчелекне һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат тарафыннан башкарыла;

ришвәтчелек юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләүче билгеле вазифа башкаручы затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә хезмәт мәгълүматларының һәм конфиденциаль характердагы мәгълүматларның сакланышы өчен җаваплы.

3. Әлеге боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитеты рәисе урынбасары И.Г. Багаутдиновка йөкләргә.

Рәис Р.Н. Сабиров

Татарстан Республикасының Сатып
алулар буенча дәүләт комитетының
2022 нче елның 30 нчы сентябрендә
чыгарылган 04-05-180 номерлы
боерыгы белән
расланган

Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетына килгән ришвәтчелек юнәлешендәге фактлар буенча гражданнар мөрәҗәгатьләре белән эшләү тәртибе

1. Әлеге Тәртип 2003 нче елның 12 нче маенда кабул ителгән “Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында” 16-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 нче маддәсен үтәү йөзеннән эшләнгән һәм Татарстан Республикасының Сатып алулар буенча дәүләт комитетына (алга таба – дәүләт комитеты) килгән ришвәтчелек һәм янап алу, гражданнарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен чикләү, хезмәт тәртибе таләпләрен бозу фактлары турында мәгълүматларны үз эченә алган ришвәтчелек юнәлешендәге фактлар, шулай ук Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәрләренең дәүләт комитетында хезмәт урыныннан явызларча файдалану билгеләре булган (алга таба – хезмәткәрләр), шулай ук Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте вазифалары булмаган һәм дәүләт комитеты эшчәнлеген техник тәэмин итүне һәм хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы вазифаларны биләүче эшчеләр (алга таба – эшчеләр) тарафыннан кылынган башка гамәлләр буенча гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау үзенчәлекләрен билгели. Башка затларга карата шундый ук фактлар турында мәгълүматлар булган мөрәҗәгать, компетенциясенә 2006 нчы елның 2 нче маенда кабул ителгән “Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” 59-ФЗ номерлы Федераль законның 8 нче маддәсенең 3 нче бүлеге нигезендә куелган мәсьәләләрне хәл итү керә торган тиешле органга яисә тиешле билгеле вазифа башкаручы затка җибәрелергә тиеш.

2. Мөрәҗәгать 2006 нчы елның 2 нче маенда кабул ителгән “Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында” 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда теркәлә һәм карала.

Мөрәҗәгатьтә әзерләнә торган, кылына торган яисә кылынган хокукка каршы гамәлләр турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында мәгълүматлар булганда, мөрәҗәгать хокук саклау органнарына, аларның компетенцияләре нигезендә, җибәрелергә тиеш.

3. Кадрлар эше алып бару өчен җаваплы хезмәткәр тарафыннан билгеләнгән тәртиптә хезмәткәргә карата хезмәт тикшерүе үткәрү башлана.

4. Хезмәт тикшерүе үткәргән комиссиянең бәяләмәсе нигезендә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән ришвәтчелек чагылышлары билгеләре булу турында фактлар расланган очракта, комиссия бәяләмәсен алганнан соң өч эш көне эчендә рәис (аның вазифаларын башкаручы зат) Татарстан Республикасының Сатып алулар һәм мәнфәгатьләр конфликтын җайга салу буенча комитетының дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибе таләпләрен үтәү комиссиясенә язма гариза бирә. Хезмәткәргә (эшчегә) карата тиешле фактлар расланган очракта, аның язма аңлатмаларын анализлаудан чыгып, аңа карата Россия Федерациясе норматив хокукый актларында каралган җаваплылык чараларын куллану мәсьәләсе хәл ителә.

Хезмәт тикшерүе нәтиҗәләре буенча әзерләнә торган, кылына торган яисә кылынган хокукка каршы гамәлләр турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында мәгълүм булса, тиешле мәгълүмат, комиссия бәяләмәсен алганнан соң бер эш көне эчендә хокук саклау органнарына, аларның компетенцияләре нигезендә, җибәрелергә тиеш.

5. Мөрәҗәгать җибәргән гражданга җавап әзерләү дәүләт комитетында ришвәтчелекне һәм башка хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы зат тарафыннан башкарыла.

6. Мөрәҗәгатьтә җаваплы затка карата ришвәтчелек юнәлешендәге фактлар турында мәгълүмат булса, әлеге зат аны карауда катнашмый, үз кандидатурасын үзе кире кагуны белдерә. Мондый мөрәҗәгатьне карау дәүләт комитетында әйдәп баручы белгеч – хокукый тәэмин итү буенча белгеч тарафыннан башкарыла.